**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 23 июнь № 433

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибен раслау хакында» 2016 ел, 4 февраль, 61 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибен раслау хакында» 2016 ел, 4 февраль, 61 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 16 апрель, 234 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9 пунктның өченче абзацында «электрон рәвештә –» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына һәм» сүзләрен өстәргә;

10 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм министрлыклар Заявканы үзләре компетенциясенә караган мәсьәләләр өлешендә карап тикшерәләр һәм Гариза бирүченең инвестицион планы бизнес-проектын түбәндәгеләргә анализлыйлар:»

12, 13, 16 пунктларда, 20 пунктның беренче абзацында тиешле килешләрдә «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков